# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елда Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Үчәлле авыл җирлеге Үчәлле
авылында гражданнардан
үзара салым кертү турында

**17.11.2023 ел** **№ 2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1,56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45- ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлегендә гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2024 елда 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан һәм гаилә әгъзасы махсус хәрби операциягә мобилизацияләнгән гаиләләрдән, күпбалалы гаиләләрдән тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 250 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Үчәлле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

-Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (тракторчы белән техниканы арендалау, сыйдырышлылыкны арендалау, янгын гидрантларын карап тоту);

- Утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

- Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын карап тоту, ремонтлау (юлларны кардан чистарту буенча чит оешмаларның хезмәтләре);

-Халыкның күпләп ял итү урыннарын (паркларны, балалар уен спорт мәйданчыкларын, башка күпләп ял итү урыннарын) һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (территорияне чабу, чистарту һәм чүп җыю буенча хезмәтләр);

- Традицион күмү урыннарын төзекләндерү (чүп чабу, агач һәм куакларны кисү буенча хезмәтләр).

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Үчәлле авыл җирлеге мәгълүмати стендында (Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Үчәлле авылы, Совет урамы, 51 нче йорт), Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында

(http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Үчәлле авыл җирлеге Башлыгы Г.М.Төхвәтуллина